Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«19» ноябрь, 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Калмаш авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2021 елда яшәү урыны буенча Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:
- Калмаш авылында юлларны төзекләндерү;
- юлларны төзекләндерү өчен вак таш, асфальт түшәк сатып алу һәм кайтару;
- Калмаш авылында электроматериаллар сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыруны;
- Калмаш авылы Зөфәр Галиев урамы буенча урнашкан канализацияне реконструкцияләү һәм материаллар сатып алу;
- Калмаш авылы зиратын койма белән уратып алу өчен материаллар сатып алу һәм урнаштыру;
- Калмаш авылында язгы ташу вакытында су басуны булдырмау өчен су бүлү каналларын эшләүне
- Калмаш авылы - З. Галиев - Үзәк урамы – Яр Чаллы – Калмаш – Игенче автомобиль юллары арасындагы участокка тимер бордюр урнаштыру.

2. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Калмаш авыл җирлеге Башлыгы Р.К.Габдуллина